КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 июль г.Казань № 728

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 438 нче карары белән расланган Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 ел, 8 июнь, 438 нче карары белән расланган Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты

турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда баш эш итүче тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Баш эш итүче, сайлап алуны үткәрү срогы башланганга кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

субсидия бирү максаты;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

баш эш итүченең исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почтасы адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 5 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 8 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе һәм заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм баш эш итүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).»;

19 пунктта:

алтынчы абзацта «ирешү турында хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләренә» сүзен өстәргә, татар текстында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, шулай ук субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата баш эш итүче тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы;»;

26 пунктта «ирешү турында хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләренә» сүзен өстәргә, татар текстында «нәтиҗәләренә» сүзен «нәтиҗәләре» сүзенә алмаштырырга;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Баш эш итүче субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары тикшерүне Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашыра.»;

28 пунктның бишенче абзацында «ирешү турында хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләренә» сүзен өстәргә, татар текстында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

30 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

«31. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.».

2. Тәртипнең 5 пунктындагы бишенче абзацының һәм 8 пунктындагы алтынчы абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның утыз беренче һәм утыз икенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин